ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 сентябрь 2018ел № 4995

«2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карары (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 нчы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 нче, 2016 елның 20 маендагы 2539 нчы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 нче карарлары редакциясендә) белән расланган «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 бүлекнең 1 пунктын 1 нче кушымтада каралганча пунктчалар белән тулыландырырга;

2) 4 бүлекнең 5 пунктын 2 нче кушымтада каралганча пунктчалар белән тулыландырырга;

3) 4 бүлекнең 6 пунктын 3 нче кушымтада каралганча пунктчалар белән тулыландырырга;

4) 5 бүлекне 4 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4995 нче карарына
1 нче кушымта

4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручы | Үтәү срогы | Көтелгән нәтиҗә | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау | Еллар буенча чыгымнар суммасы, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 2018 | 2019 | 2020 |
| 1. Коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү | | | | | | | | |
| 21.1) | Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында законнарының мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салуга кагылышлы таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, билгеләнгән таләпләрне үтәмәүче затларны дисциплинар җаваплылыкка тарту | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы стандартының кимчелексез үтәлешенә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 21.2) | Кадрлар эшенең муниципаль вазыйфа һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның шәхси делоларын алып баруга кагылышлы, шул исәптән мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау максатында күрсәтелгән вазыйфаларга билгеләнгәндә һәм шундый хезмәткә урнашканда тапшырыла торган анкеталардагы мәгълүматларның актуальлеген контрольдә тоту өлешендә нәтиҗәлелекне күтәрү буенча чаралар күрү | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфа биләүче затларның анкеталарындагы мәгълүматларның дөреслеген арттыру | Чара оештыру характерына ия | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21.3) | Норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләү өчен муниципаль хезмәткә беренче тапкыр урнашкан муниципаль хезмәткәрләрне коррупциягә каршы тору өлкәсендә белем бирү программалары буенча махсуслаштырылган укыту | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендә белемнәрне арттыру | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 21.4) | Вазыйфаи бурычларына коррупциягә каршы торуда катнашу кергән муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен ел саен махсуслаштырылган күтәрү | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затларның һөнәри осталыгын арттыру | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 21.5) | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның, муниципаль районнарда эш итүче иҗтимагый совет әгъзаларының Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының коррупциягә каршы тору турында законнарының таләпләре һәм аларны бозган өчен җәзаның котылгысыз булуы турында хәбәрдарлыгын арттыру буенча чаралар күрү | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар үтәлешенә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 21.6) | Ведомство карамагындагы оешмаларның уставларына, ведомство карамагындагы оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре арасындагы хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы нормалар өлешендә үзгәрешләр кертү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә каршы сәясәт үтәлешенә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21.7) | Ведомство карамагындагы оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан ведомство карамагындагы оешмаларның уставларының һәм хезмәт килешүләренең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм/яки җайга салуга кагылышлы таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту, әлеге таләпләр үтәлмәгән очракта, җаваплылыгына мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы таләпләр кагыла торган затларны җәлеп итеп, аны булдырмау һәм/яки җайга салу буенча чаралар күрү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә каршы сәясәт үтәлешенә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4995 нче карарына
2 нче кушымта

4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручы | Үтәү срогы | Көтелгән нәтиҗә | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау | Еллар буенча чыгымнар суммасы, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 2018 | 2019 | 2020 |
| 5. Дәүләт һәм муниципаль органнарның халык өчен ачыклыгын һәм мөмкинлеген тәэмин итү, аларның гражданнар җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | | |
| 57.1) | Җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрү (эксперизa берләшмәләрен, иҗтимагый совет әгъзаларын җәлеп итеп). Муниципаль районда эш итүче коррупциягә каршы тору буенча муниципаль программаны тормышка ашыру турында хисаплар, коррупциягә каршы тору буенча муниципаль программаны тормышка ашыру турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтның «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштыру | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Ачыклыкны һәм хәбәрдарлыкны тәэмин итү | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 57.2) | Коррупциягә каршы тору буенча муниципаль программаны тормышка ашыру турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтның «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштыру. | Шәһәр Советы (килешенү буенча), Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Ачыклыкны һәм хәбәрдарлыкны тәэмин итү | Чара оештыру характерына ия | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4995 нче карарына
3 нче кушымта

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручы | Үтәү срогы | Көтелгән нәтиҗә | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау | Еллар буенча чыгымнар суммасы, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 2018 | 2019 | 2020 |
| 6. Муниципаль заказ урнаштыру буенча эшчәнлекне оештыруны камилләштерү | | | | | | | | |
| 59.1) | Сатып алуда катнашучы һәм заказчы арасында мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүне, шулай ук башка хокук бозуларны булдырмау максатында, ведомство карамагындагы оешмаларның «Аерым төр юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган сатып алуларын анализлауны үткәрү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекнең ачыклык дәрәҗәсен күтәрү | Чара оештыру характерына ия | | | |
| 59.2) | Контрактның башлангыч (минималь) бәясе 5 млн. сумнан арткан очракта, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы үткәрү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекнең ачыклык дәрәҗәсен күтәрү | Чара оештыру характерына ия | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4995 нче карарына
4 нче кушымта

5 бүлек. «Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары
һәм программа чаралары буенча финанслау»

| Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелегенең төп индикаторлары | Төп чараларны үтәү сроклары | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|
| 1. | 2. | 3. | 4. |
| Яр Чаллы шәһәрендә коррупция дәрәҗәсе (Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайты аша социалогик сораштыру үткәрү юлы белән алынган мәгълүматлар буенча), % | ел саен | 35 | 40 |
| Коррупция буенча хокук бозган муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфа биләүче затлар саны, кеше | ел саен | 13 | 11 |
| Тикшерү нәтиҗәсендә хокук бозулар ачыкланган коррупция күренешләренә юлыккан гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренең өлеше, гомуми мөрәҗәгатьләр санынннан, % | ел саен | 2 | 2 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова